| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПИСЬМЯНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ПИСМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның 30 октябре №8

Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Савочкино торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.2023елның 19 ноябренә Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге Савочкино торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе. буенча гражданнарның җыенын 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Сез 2024 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге Савочкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балачактан инвалидлар, шулай ук I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннары; көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

Җирлек территориясен төзекләндерү күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы итеп, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә ирешү мөмкинлеген тәэмин итү таләпләрен үтәү:

Лесная урамында урам яктыртуына техник хезмәт күрсәтү;

торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Лесная урамындагы юлларны кардан чистарту;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Подлесный бистәсе, Гагарин урамы, 5 нче йорт, Подлесный бистәсе, Гагарин урамы, 1б йорт, Иске Писмән авылы, Үзәк урам, 50 нче йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов